# **КАРАР**
## **Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советы**

Илбәк авылы №132 «12» июль 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 24.11.2014 ел №106 карарына (18.08.2015 елның 130 номерлы, 24.04.2018 елның 87 номерлы, 15.11.2018 елның 109 номерлы, 27.12.2018 елның 114 номерлы карарлар редакциясендә) үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турында аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 15.04.2008 елдагы 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезедә

Илбәк авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 24.11.2014 ел №106 карарына (18.08.2015 елның 130 номерлы, 24.04.2018 елның 87 номерлы, 15.11.2018 елның 109 номерлы, 27.12.2018 елның 114 номерлы карарлар редакциясендә), 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«3.2. Салым ташламасы салым түләүче тарафыннан салым түләүченең милкендә булган һәм салым түләүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым объектына карата түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасын билгеләгәндә салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына карамастан, салым түләүченең теләге буенча һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы, салым салуның мондый объектларында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннардан тыш, Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларына карата бирелми.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламаларын бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүченең

салым ташламасына хокукынраслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

Әгәр дә салым түләүче Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктның 2, 3, 10, 10.1, 12, 15 пунктчаларда күрсәтелгән затларның бер категориясенә керсә һәм салым ташламасына хокукы булып та, салым органына салым ташламасын бирү турында гариза тапшырмаган яисә салым ташламасын кулланудан баш тарту турында хәбәр итмәгән булса, салым ташламасы салым органы тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексы һәм башка федераль законнар нигезендә алынган белешмәләр нигезендә бирелә.

Үзе сайлап алган, салым ташламасы бирелә торган салым объектлары турында хәбәрнамә салым чоры булып торган елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча салым түләүче тарафыннан салым органына тапшырыла, әлеге периодтан алып күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче сайлап алынган салым ташламасы турында хәбәрнамәне тапшырмаган очракта салым ташламасы салым салуның иң чик исәпләнгән суммасы белән салым салу объектларының һәр төренең бер объектына карата бирелә.».

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 24.11.2014 ел №106 карарындагы (18.08.2015 елның 130 номерлы, 24.04.2018 елның 87 номерлы, 15.11.2018 елның 109 номерлы, 27.12.2018 елның 114 номерлы карарлар редакциясендә), 3.2 пунктының 5нче абзацындагы нигезләмә 2018 елның салым чорыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарны район «Маяк» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//aznakayevo.tatar.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Р.Әсәдуллина